ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

27.06.2024 № 580

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы бюджетыннан күчмә сәүдә алып бару өчен махсус автотранспорт сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә кулланучылар кооперациясе оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 13 июлендәге 694 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы бюджетыннан күчмә сәүдә алып бару өчен махсус автотранспорт сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә кулланучылар кооперациясе оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 13 июлендәге 694 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Биектау муниципаль районы бюджетыннан күчмә сәүдә алып бару өчен махсус автотранспорт сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә кулланучылар кооперациясе оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе дип аталган 1 нче кушымтаның 2.1 пунктындагы 4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясендә (алга таба-офшор компанияләре) активларга арадаш (офшор) биләү өчен кулланыла торган Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләрнең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше җыелмасы 25 проценттан артып киткән (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса) россия юридик заты булып тормый. Россия юридик затлары капиталында офшор компанияләрнең катнашу өлешен исәпләгәндә офшор

компанияләренең акцияләре Россия Федерациясендә оештырылган сату-алуларда әйләнгән гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында (шул исәптән халыкара компания статусы белән) турыдан-туры һәм (яисә) читләтеп катнашуы, шулай ук күрсәтелгән гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашу аша гамәлгә ашырылган башка Россия юридик затларының капиталында офшор компанияләренең читләтеп катнашуы исәпкә алынмый;»

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин